# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Чулпан торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**30 ноябрь 2024 ел** **№ 5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Чулпан торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Чулпан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 90 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар,СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, күп балалы гаиләләрдән тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Чулпан торак пунктына кергәндә авыл эчендәге юлларны ремонтлау( вак таш сатып алу, ташу, шартнамә буенча түләү).

3.Әлеге карарны Николаевка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Николаевка авыл җирлеге
башлыгы урынбасары ______________/В.А.Липин